**СОВЕТ ТАШЛЫ-КОВАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422716, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Ташлы-Ковали, ул.Центральная, 68

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШЛЫ КАВАЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422716, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Ташлы Кавал авылы, Узэк ур.68

Тел./факс: +7(84365) 79-4-03, e-mail:Alder.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**21 апрель 2021 г.** **№ 24**

## Ташлы Кавал авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 мартындагы 143 номерлы карары белән расланган Ташлы Кавал авыл җирлеге территориясендә Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына территорияләрне комплексны үстерүне тәэмин итү максатларында үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы  Ташлы Кавал авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Ташлы Кавал авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 мартындагы 143 номерлы карары белән расланган Ташлы Кавал авыл җирлеге территориясендә Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, 12 статьяда:

а) өченче абзацны «,әлеге статьяның дүртенче абзацында билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләре белән тулыландырырга.»;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац белән тулыландырырга:

«Территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.»;

в) дүртенче, бишенче һәм алтынчы абзацларны тиешле тәртиптә бишенче, алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга;

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.И.Хайбуллин